ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 12 » февраль 2021 ел** **№ 78**

**2021 елдан башлап өч елга кулланыла торган муниципаль энергетика ресурсларының һәм суның суммар күләмен чагыштырма шартларда киметү буенча максатчан дәрәҗә билгеләү турында**

«Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 23 ноябрендәге Федераль законга, «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре тарафыннан кулланыла торган дизель һәм башка ягулык, мазут, табигый газ, җылылык энергиясе, электр энергиясе, күмер күләменең, шулай ук алар куллана торган суның суммар күләмен чагыштырма шартларда киметүгә карата таләпләр турында» 2019 елның 7 октябрендәге 1289 номерлыРоссия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре тарафыннан кулланыла торган дизель һәм башка ягулык, мазут, табигый газ, җылылык энергиясе, электр энергиясе, күмер күләмнәренең, шулай ук алар куллана торган су күләменең чагыштырма шартларында кимүенә карата таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 23 июнендәге 914 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре тарафыннан кулланыла торган дизель һәм башка ягулык, мазут, табигый газ, җылылык энергиясе, электр энергиясе, күмер күләмнәренең, шулай ук алар куллана торган суның күләмен киметүнең максатчан күләмен чагыштырма шартларда билгеләү буенча методик рекомендацияләрне раслау турында» Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының 2020 елның 15 июлендәге 425 номерлы боерыгы нигезендә, муниципаль учреждениеләрнең энергия нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Тиешле шартларда муниципаль учреждениеләр тарафыннан кулланыла торган энергетика ресурсларының һәм суның суммар күләмен 2021 елдан

башлап өч елга киметүнең максатчан дәрәҗәсен кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» МКУнә йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Мөхәрәмов